ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 50 (I өлеш); Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2017 елның 4 декабре), түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

“4. 2013 елның 1 гыйнварыннан төп чара буларак исәпкә куелган күчемле мөлкәткә карата салым ставкасы 2018 елда 1,1 процент күләмендә билгеләнә, моңа түбәндәгеләр нәтиҗәсендә исәпкә куелган әлеге күчемсез мөлкәт объектлары керми:

юридик затларны яңадан оештыру яисә юкка чыгару;

Россия Федерациясе Салым кодексының $105^1$ статьясының 2 пункты нигезләмәләре буенча үзара бәйле дип танылган затлар арасында мөлкәт тапшыру, сатып алуны да кертеп.

Әлеге өлешнең икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән чыгарылмалар 2013 елның 1 гыйнварыннан җитештерелә башлаган тимер юл хәрәкәт составына карата кулланылмый. Тимер юл хәрәкәт составын эшләп чыгару датасы техник паспортлар нигезендә билгеләнә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 22 декабрь
№ 97-ТРЗ